СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

14.12.2018 | с. Верхний Услон | № 39-447

## Югары Ослан муниципаль районы территориясендә җирләрдән нәтиҗәле файдалану һәм муниципаль мөлкәт белән идарә итү турында

Югары Ослан муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Л.П. Потапованың Югары Ослан муниципаль районы территориясендә җирләрне рациональ һәм нәтиҗәле файдалану һәм муниципаль милек белән идарә итү турында мәгълүматны тыңлап,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә җирләрне рациональ һәм нәтиҗәле файдалану һәм муниципаль милек белән идарә итү турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Югары Ослан муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына:

- физик һәм юридик затлар җир кишәрлекләреннән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруны көчәйтергә, тиешенчә файдаланмау фактларын ачыкларга;
- җирле бюджетка салымнар түләү буенча бурычларны түләп бетерү буенча җирдән файдаланучылар белән даими рәвештә профилактик эш алып барырга;
- муниципаль район территориясендә урнашкан файдаланылмый торган һәм нәтиҗәсез файдаланыла торган муниципаль мөлкәтне ачыклау эшен активлаштырырга
- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән берлектә Югары Ослан муниципаль районында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге файдаланылмаган җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы әйләнешенә кайтару эшен дәвам итәргә

3. Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү буенча фермер хуҗалыклары белән эшне дәвам итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, экология, табигый ресурслар һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль район Башлыгы урынбасары С.В. Осянин